# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2011, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә:

а) икенче абзацта «һәм документаль рәвештә (кәгазь саклагычларда)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон рәвештәге муниципаль норматив хокукый актның кәгазь саклагычтагы акт эчтәлегенә туры килүен билгеләү максатларында вәкаләтле орган таләбе буенча соратып алына торган акт тиешле җирле үзидарә органы мөһере һәм вәкаләтле вазыйфаи зат имзасы белән таныкланган рәсми күчермәсе рәвешендә тапшырыла.»;

2) 4 статьяның 1 өлешендә:

а) икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) өченче абзацта «Электрон рәвештәге муниципаль норматив хокукый актлар» сүзләрен «Муниципаль норматив хокукый актлар электрон рәвештә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 12 гыйнвары
№ 7-ТРЗ